МИНИСТЕРСТВО ТРАНСПОРТА
И ДОРОЖНОГО ХОЗЯЙСТВА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТРАНСПОРТ ҺӘМ ЮЛ
ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

**БОЕРЫК** **ПРИКАЗ**

12.08.2022 № 248

Казан шәһәре

Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы территориясе буенча пассажирлар йөртү һәм багаж алып баруның даими муниципальара маршрутлары буенча пассажирлар йөртү һәм багаж алып баруны гамәлгә ашыру хокукына ачык конкурста катнашучыларның гаризаларын бәяләү өчен критерийлар шкаласын раслау турында» 2016 елның 9 мартындагы 94 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү турында

Б о е р ы к б и р ә м:

Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы территориясе буенча пассажирлар йөртү һәм багаж алып баруның даими муниципальара маршрутлары буенча пассажирлар йөртү һәм багаж алып баруны гамәлгә ашыру хокукына ачык конкурста катнашучыларның гаризаларын бәяләү өчен критерийлар шкаласын раслау турында» 2016 елның 9 мартындагы 94 номерлы боерыгына (Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының 2018 елның 14 сентябрендәге 459 номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәреше белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасында автомобиль транспортында һәм җир өсте шәһәр электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж алып баруның муниципальара маршрутлары буенча пассажирлар йөртү һәм багаж алып бару хокукына ачык конкурста катнашучыларның гаризаларын бәяләү критерийлары өчен шкала раслау турында»;

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм җир өсте шәһәр электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж алып баруны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы федераль законны һәм «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм җир өсте шәһәр электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж алып баруны оештыруның аерым мәсьәләләре турында» федераль законны гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 26 декабрендәге 107-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын үтәү максатларында боерык бирәм:»;

1 пунктта «Татарстан Республикасы территориясе буенча даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж алып бару» сүзләрен «Татарстан Республикасында автомобиль транспортында һәм җир өсте шәһәр электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж алып бару» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктта «А.В.Сидорова» сүзләрен төшереп калдырырга;

күрсәтелгән боерык белән расланган Татарстан Республикасы территориясе буенча ташуларның даими муниципальара маршрутлары буенча ташуларны гамәлгә ашыру хокукына ачык конкурста катнашучыларның гаризаларын бәяләү өчен критерийлар шкаласында:

Исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасында автомобиль транспортында һәм җир өсте шәһәр электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж алып баруның муниципальара маршрутлары буенча пассажирлар йөртү һәм багаж алып бару хокукына ачык конкурста катнашучыларның гаризаларын бәяләү критерийлары өчен шкала»;

2 пунктның «критерийлары/параметрлары» графасында «даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж алып баруны гамәлгә ашыру» сүзләрен «Татарстан Республикасында автомобиль транспортында һәм җир өсте шәһәр электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж алып баруны гамәлгә ашыру (алга таба – даими йөртү)» сүзләренә алмаштырырга.

Министр Ф.М.Хәнифов